Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

16 декабрь 2021 ел № 114

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Кадрлар үзгәреше белән бәйле рәвештә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы « Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә хакында »гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 12 мартындагы 367 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 12 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 36 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- карарга «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе составы» 2 нче кушымтада:

а) комиссия составыннан Л.Ф. Вәлиевне чыгарырга;

б) комиссия составына Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссия рәисе Грушин Алексей Ивановичны кертергә.

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә. Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов